БЕРДӘМЛЕКТӘ – КӨЧ
Уртак эшмәкәрлекнең өстенлеге нәрсәдә?
> 2

ӘЛИФБА МУЗЕЕ
Биредә сигез экспозициягә 160 дәреслек куелган, алар – дөньяның 72 телендә.
> 3

ҖЫРЧЫ ИЛСУР САФИН:
«Ходайдан хәзер исәнлек кенә сорыйм»
> 4

САВАПЛЫ СУ
Имәнкискә һәм Столбище халкы «Чишмә»ле булды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 126 (28899) | Сишәмбе | 30 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Вакыйга

Яшьләрне борчымаган өлкә юк. Узган атна шимбәсеннән башлап бүгенгә кадәр Казан шул сорауларны уртага салып сөйләшү үзәге булып торды. Башкалада Яшь дипломатлар глобаль форумы һәм Яшьләр глобаль саммиты узды. Ике чараның әһәмияте нәрсәдә һәм аларның нәтиҗәсе нинди булыр?

tatarstan.ru

КИЛӘЧӘКНЕ УЙЛАП

Сөйләшәсе сүзләр бар

Берләшү һәм хезмәттәшлек итү. Хәзерге чорда бу бигрәк тә мөһим. Яшь дипломатлар форумының төп эчтәлеген дә шушы ике сүзгә бәйләп булыр иде. Сүз уңаеннан, ул үз тарихында бишенче, ә Казанда тәүге мәртәбә оештырыла. Форумга 50 илдән 129 делегат җыелды. Болар – булачак дипломатлар, халыкара мөнәсәбәтләр буенча белгечләр, тышкы эшләр министрлары.

Форумның фикер алышу өчен сайланган мәсьәләләре дә хәзерге дөнья өчен актуаль. Әйтик, киберкуркынычсызлык, цифрлаштыру, замана шартларында дипломатия кору мөмкинлекләре, яшьләрнең миграциясе.

Бу чараның Казан һәм, гомумән караганда, бөтен дөнья өчен әһәмияте нидә соң? Форумда күп тапкыр яңгыраган төп фикердән аңлашылганча, тиз үзгәрүчән дөньяның язмышы нәкъ менә бүгенге яшьләр җилкәсенә төшәчәк. Шуңа да аралашырга кирәк.

Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров фикеренчә, замана үзәккә чыгарган күпсанлы мәсьәләләрне билгеле нормалар кысасында да хәл итәргә мөмкин.

– Хәзерге шартларда аралашуны туктатырга түгел, киресенчә, арттырырга кирәк. Бу җәһәттән дипломатиянең дә роле арта. Аны артка чигерергә тырышкан өлкәләрдә явызлык һәм гегемония калкып чыга, моның нәтиҗәләре исә бик аянычлы. Халыкара аренада ышаныч һәм үзара аңлашу мохитен саклау буенча уртак эшкә менә шушындый очрашулар да үз өлешен кертә, – диде ул, катнашучыларга видеоэлемтә аша мөрәҗәгать итеп. – Россия тынычлык сөюче тышкы сәяси курсны алып баруын дәвам иттерә. Без – халыкларның мәдәни-цивилизацион күптөрлелеген хөрмәт итү тарафдарлары.

Федерация Советы Рәисе урынбасары Константин Косачев әйтүенчә, хәзерге вакытта дөньякүләм дипломатия коруда кыенлыклар бар.

– Һәр низагның нигезендә бер-береңне ишетергә теләмәү һәм каршы якның мәнфәгатьләрен инкарь итү ята. «Без» һәм «алар» дип ешрак сөйлибез. Мондый мантыйк дипломатия өчен начар. Упкынга төшәргә санаулы мизгелләр калганда, кешелекнең бер-берләре белән килешүдән башка юлы калмый. Яңа буын дипломатларга зур өметләр баглыйм, – диде ул.

Россия Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтының (МГИМО) кадрлар сәясәте буенча проректоры Владимир Морозов форумның әһәмияте турында менә нинди фикердә:

– Минем уйлавымча, бу чара Россия өчен генә түгел, белем бирү, мәгариф җәмәгатьчелеге өчен дә әһәмияткә ия. Гадәти булмаган халыкара вазгыятьтә кемнәрнең безнең белән хезмәттәшлек итүен аңлау бик мөһим. Безнең ил сөйләшүгә һәрвакыт ачык. Чит ил студентларының да безнең белән араларны өзмәве күзәтелә. Әйтик, МГИМОда дөньяның 65 иле университетлары белән хезмәттәшлек итү турында 200ләп килешүебез бар. Аның күпчелеге – Европа илләре белән. Әлегә ул килешүләрне өзү турында сүз кузгатучы юк. Яхшы дипломатия яхшы белгечләрдән барлыкка килә.

Форумда катнашучыларны сәламләргә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та килгән иде. Ул да яшь дипломатлар җилкәсендәге җаваплылыкның зур булуын искәртте.

– Халыкара мөнәсәбәтләрнең киләчәге өчен җаваплылык күп очракта дипломатлар җилкәсенә төшә. Нәтиҗәнең уңышлы булуы сезнең гомуми әзерлеккә, үзара файдалы шартлар эзләүгә дә бәйле. Һөнәри үсешегез өчен менә шушындый очрашу мәйданчыкларының әһәмияте зур, – диде ул, делегатларга мөрәҗәгать итеп. – Тышкы сәяси вазгыятьнең нинди булуына карамастан, монда килгән делегатларның күплеге куандыра. Бу инде фикер алышуга карата кызыксыну зур булу турында да сөйли.

Татарстанның халыкара мөнәсәбәтләрне көйләүдәге өлешен Россия Тышкы эшләр министрлыгының мөселман дәүләтләре оешмалары белән хезмәттәшлек итү буенча махсус вәкиле, министрлыкның махсус йөкләмәләр буенча илчесе Константин Шувалов та югары бәяләде.

– Татарстан берләшергә һәм хезмәттәшлек итәргә мөмкинлек бирә. Казан – хезмәттәшлекнең яңа формалары барлыкка килә торган очрашулар өчен бик яхшы урын, – дип билгеләп үтте ул. – Дипломатларның шәхсән очрашып, аралашулары да – чараның бер үзенчәлеге. Эш урынында әйтә алмаганны шул рәвешле әйтеп була. Ирекле мохит хөкем сөрә. Кайбер мәсьәләләргә яшьләрнең карашы да кирәк.

Ахыры 2 нче биттә >

Тимур СӨЛӘЙМАНОВ, Татарстан яшьләр эшләре министры:
– Көтелгән өметләр акланды. Бу катнашучылар географиясендә дә, күтәрелгән сораулар, катнашучыларның статусында да чагылды. Көн тәртибендәге барлык сессияләр дә үткәрелде. Шунысы да мөһим: очрашулар оештырганда да, һәр як өчен дә файдалы, кызыклы булырдай якларны барладык, килешүләр төзелде. Инде хәзер гамәлләргә дә тотынырбыз.
Татарстанда халыкара яшьләр үзәген булдыру идеясен күпләр үз итте һәм хуплады. Ул Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре арасындагы элемтәләрне ныгытуга һәм ярдәм итүгә булышыр иде. Әлегә төгәл вакыт турында әйтергә иртәрәк. Моның буенча фикер алышулар булачак. Үзәкне булдыру безгә башка илләр белән төрле тармаклар буенча элемтәдә торырга ярдәм итәчәк.
Яшьләр белән элемтә урнаштыруның юлларын гел эзләргә кирәк. Иң мөһиме – аларга кызык булсын. Аннан, без яшьләрдән качарга тиеш түгел. Алар кайда – без шунда булыйк. Әгәр алар парк һәм скверларда икән, шунда чыгарга, сәүдә йортында икән – шунда нидер булдырырга. Яшьләр сәясәтенең субъекты да – яшьләр үзләре.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ КОТЛЫ БУЛСЫН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВ МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне дәүләт бәйрәмнәребезнең иң әһәмиятлесе – Республика көне уңаеннан ихлас йөрәктән тәбрик итәм.

Татарстан – төрле халык һәм дин вәкилләре дус-тату яши торган зур гаилә.

Бу бәйрәм туып-үскән, гомер иткән газиз җиребезгә карата ярату хисләребезне тагын да көчәйтә, безне якынайта, берләштерә.

Ата-бабаларыбызның тиңдәшсез батырлыклары турындагы хәтер-хатирәләр безнең өчен һәрчак изге, без дөньяны фашизмнан азат иткән данлыклы җиңүчеләр буынының каһарманлыгы белән хаклы төстә горурланабыз. Донбасста яшәүчеләрне яклауга һәм тыныч тормыш урнаштыруга юнәлтелгән чараларны хуплыйбыз. Күпмилләтле халкыбызның рухи-әхлакый хәзинәләре, традицияләренең безнең өчен кыйммәте зур һәм без аларны аеруча мөһим дип саныйбыз.

Татарстанлыларның бәрәкәтле хезмәте нәтиҗәсендә, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте булышлыгы белән республикабыз үсә бара, күп кенә икътисади күрсәткечләр буенча илнең алдынгы төбәкләре арасында тотрыклы урын били. Сәнәгать, энергетика, торак һәм юл төзелеше өлкәсендә, авыл хуҗалыгында колачлы проектлар гамәлгә ашырыла. Без хәзерге вакытта IT өлкәне үстерү, яңалыклар, заманча технологияләр кертү юнәлешендә тырышлык куябыз.

Икътисадтагы уңышлар татарстанлыларның тормышын яхшыртуга бәйле төп бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә. Җәмгыять өчен гаять әһәмиятле программаларны, федераль һәм республика проектларын гамәлгә ашыру әлеге зур максатка ирешүгә ярдәм итә. Кешеләргә көн итү өчен уңайлы мохит булдырыла. Ямьле парк-бакчалар, чәчәклекләр, су буйлары, елга ярлары, яшел мәйданчыклар балалар, яшьләр һәм өлкәннәрнең яратып ял итә торган урынына әйләнде.

Милләтләр һәм диннәр арасындагы тынычлыкны, гражданнарның татулыгын саклау һәм ныгыту – һәрчак игътибар үзәгендә. Мәдәниятләр һәм диннәр күптөрлелеге – бәхәссез өстенлекләребезнең берсе. Идел буе Болгар дәүләтенең рәсми төстә ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуны бәйрәм итү һәм Россия халыкларының мәдәни мирасы елын уздыру быелның иң истәлекле вакыйгалары булды. Бу уңайдан үткәрелә торган чаралар дәүләт белән диннең үзара хезмәттәшлеген, динара аңлашуны көчәйтүгә, телләр, мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерүгә, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы бердәмлеген ныгытуга ярдәм итә.

Хөрмәтле татарстанлылар, республикабызның алгарышы – уртак хезмәтебез җимеше, алдагы көннәргә ышанычыбыз һәм якты өметләребез нигезе. Без бергәләп Татарстанны яшәү өчен иң гүзәл җир итәргә һәм шул рәвешендә киләчәк буыннарга тапшырырга омтылабыз.

Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!

Татарстан Республикасы көне мөбарәк булсын!

COVID-19

Саумы, битлек!

ТАТАРСТАНДА КОРОНАВИРУСКА КАРШЫ КӨРӘШ ЧАРАЛАРЫ КАТГЫЙЛАНА

Янә битлек кияр чак! Белгечләр коронавирусның тормышыбызга кабат әйләнеп кайтуы турында кисәтә. Республикада ковид йоктыручылар саны тәүлек саен артканнан-арта бара. Атна ахырында узган киңәшмәдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та итәк-җиңнәрне җыяр чак җиткәнне искәртте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Белгечләрнең август азагына биргән фаразы да рас килә. Хәтерләсәгез, Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков «Мәскәүдә коронавирус белән авыручылар саны арта башласа, ике-өч атнадан безнең республикада да бу чирне йоктыручылар күбәя», – дигән иде. Шулай булып чыкты да.

Рәсми саннардан күренгәнчә, бер атна эчендә Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны 47 процентка арткан. Соңгы бер тәүлек эчендә генә дә республикада коронавирус йоктыруның 247 яңа очрагы теркәлгән. Республикада мондый хәлнең майдан бирле күзәтелгәне булмаган. Бер атна эчендә коронавирус йоктырып, хастаханәгә озатылучылар саны да 1,4 тапкыр арткан. Пандемия башланганнан бирле Татарстанда ковид белән авыручылар саны 156620гә җиткән. Шул чорда барлыгы 150799 кеше чирне җиңгән, 2 мең кешенең гомере өзелгән.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шимбә көнне узган киңәшмәдә коронавируска каршы көрәш буенча оператив штаб эшчәнлеген яңартырга кушты. Президент, ковид яңадан баш калкыту сәбәпле, санитар-эпидемиологик таләпләрне катгыйландырырга кирәклеген дә искәртте.

– Вакцинацияне дә көчәйтергә кирәк. Хезмәт коллективлары җитәкчеләренә, бюджет тармагы вәкилләренә мөрәҗәгать итәм: барлык санитар-эпидемиологик таләпләр, шул исәптән битлек режимы да үтәлергә тиеш. Үзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз! – диде Президент.

Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, бүген коронавирус, нигездә, кондиционер янында озак утырганнан соң салкын тию кебегрәк формада уза. Кеше тамак авыртудан зарлана, төкерек йоту авырлаша. Температура да күтәрелергә мөмкин. Чирне кисәтү өчен вакытында прививка ясатырга киңәш итә белгеч. Бүген Татарстанда барлыгы 2 миллион 490 мең кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. «Коронавируска каршы иң нәтиҗәле көрәш ысулы – вакцинация. Соңгы арада халыкның аңа булган мөнәсәбәте үзгәрде. Күпләр, чирне йоктырган очракта да, прививкалы килеш аны җиңелрәк уздырасын аңлый», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Эльмира ЗАРИПОВА, Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры:

Хезмәт хакы буенча, гадәттә, бездә һәрвакыт эшкәртү сәнәгате – нефть химиясе һәм нефть эшкәртү алдынгы урында. Аннан соң IT белгечләр бара. Шулай ук төзелештә хезмәт хаклары югары. Хәзерге вакытта предприятиеләр хезмәт хакына игътибар итәләр. Алайса, кеше эшкә килмәячәк.

(«Туры элемтә»дә сөйләгәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – УРЫП-ҖЫЮ

29 августка булган мәгълүматларга караганда, республика кырларыннан 4,2 миллион тоннадан артык уңыш җыеп алынган. Урып-җыю эшләре 1132576 гектарда башкарылган. Уртача уңыш гектарыннан 37,3 центнерны тәшкил итә.

ИҢ ЗУР УҢЫШ КАЙДА ЧЫГА?

Район	Суктырып алынган (т)	Уртача уңыш (ц/га)
Тәтеш	202156	49,1
Буа	176855	39,3
Минзәлә	164469	48,4
Мөслим	160709	38,3
Спас	155883	39,1
Актаныш	151853	39,5
Арча	149535	37,7
Чистай	146959	36,1
Сарман	145438	41,2
Нурлат	141070	36,1

Бәйрәм бүләкләре

Татарстан Республикасы көне алдыннан Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә 50дән артык кешегә дәүләт бүләкләре тапшырды. Алар арасында сәнәгать предприятиеләре һәм оешмалары вәкилләре, медицина хезмәткәрләре, иҗат эшлеклеләре, хәйриячеләр, Ватанны саклаучылар бар.

– Сезне чын күңелдән бәйрәм белән котлыйм! Бу көнне безне туган республикага булган җылы хисләр берләштерә, без монда яшибез һәм планнар корабыз. Татарстан – төрле милләт һәм дин вәкилләре тату һәм дус яши торган зур гаилә, – диде Президент. – Илнең социаль-икътисади үсеше, аның куәтен ныгыту, бүген Россия алдында торган җитди каршылыкларны уңышлы җиңеп чыгу, туган республикабызның иминлеге һәм чәчәк атуы сезгә – хезмәт, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм рухи өлкә кешеләренә, шулай ук уңышлы идарәчеләр һәм эшкуарларга бәйле.

«Казан Экспо» үзәгендә исә Президент муниципаль берәмлекләр арасында узган республика бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләде. «Авыл җирлеге, район, шәһәр һәм республика дәрәҗәсендә җайга салынган эш нәтиҗәсендә без халыкның тормышын яхшыртуга ирешәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстанда яшәүчеләрнең тормыш сыйфаты төп максат икәнен әйтте. Бәйгедә җиңгән муниципаль берәмлекләргә – «Лада Гранта» җиңел автомобильләре, шәһәр округларының муниципаль учреждениеләренә «Форд Транзит» автобуслары тапшырылды.

Тантана башланыр алдыннан Әтнә һәм Нурлат районнары Рөстәм Миңнехановка үзләрендә урып-җыю эшләре тәмамлану хөрмәтенә быелгы уңыштан пешерелгән күмәч тапшырды.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АКШ: ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ БУЛЫРМЫ?

Глобаль капитализмның иң бай илләрендә дә төшенкелек арта. Гади халык массалары гына түгел, ил лидерлары, мәшһүр сәясәтчеләр киләчәккә начар фаразлар ясый.

Франция Президенты Эммануэль Макрон: «Без бөек тетрәнүләр кичерәбез. Асылда, без кичергән нәрсә – муллык чорының бетүе. Сүз һәрвакытта да кул астында булган продуктлар һәм технологияләрнең юкка чыгуы турында бара», – дип белдерде. Лондон мэры Садик Хан энергиягә бәяләр күтәрелү фонында: «Хөкүмәт кичекмәстән хәрәкәт итә башламаса, Бөекбританияне «милли катастрофа» көтә», – дигән сүзләр әйтте. Хөкүмәт исә тик ятмый, билгеле, протестлар башланган очракка план әзерли. Бу хакта The Sun газетасы яза. Европа Берлеге депутаты Мислав Колакушич та иртәгәсе көнгә шомланып карый. «30 ел элек кытайлар ягылмаган фатирларда яши һәм велосипедларда йөри иде, чөнки шуннан артыгына ирешә алмадылар. Һәм хәзер, якындагы 30 елда без Европа Берлегендә шулай ук эшләячәкбез, чөнки үзебезгә артыгын рөхсәт итә алмабыз», – ди ул. Сәясәтчеләр хәлне кирәгеннән артык куерталар, әлбәттә. Әмма кризисның глобаль катастрофага таба хәрәкәте – чын нәрсә ул. «Кайчан?» дигән сорауга җавап кына әлегә ачык кала.

Кытай дигәннән, яңа гына муллыкка ирешкән держава бөек түнтәрелешнең флагманы булырга җыена. Анда күчемсез милек базары үрле-кырлы сикерә. Зур төзелеш компанияләренең өчтән икесе банкротлыкка чыкты яисә шул юлда. Компартиянең аларны бөлгенлектән тартып чыгарырга чарасы калмады. Банкротларны яңа басылган өстәмә акча яңгыры астында тотып тору түнтәрелешнең масштабын гына зурайта. Дәүләт хәзер яңа төзелеп, фатирлары сатылмаган күпкатлы йортларны җимерү өчен субсидия бирә башлады.

Зур бәхетсезлекнең кара сигналлары АКШтан да килә. The Washington Post газетасының өлкән редакторы Марк Фишер ял көнне газетаның басма версиясендә «Кушма Штатлар гражданнар сугышы бусагасында тора, күпләр моны котылгысыз һәм кирәк тә дип саный», – дигән фикер белдерде. Фишер океан артында ватандашлар сугышы куркынычы турында язучыларның беренчесе түгел. Бу идея анда күптән йөри инде. Ил шулай ук хәл итеп булмый торган конфликтлар стадиясендә һәм алар даими үсештә. Ил халкы югары белем өчен алган кредитларын түли алмый. Белем алган өчен җыелган әҗәтләр масштабы 1,6 триллион долларга җиткән инде. Чагыштырыгыз: Россиянең эчке тулай продукты – 1,5 триллион сум. Димәк, студент булу рәхәте өчен тупланган бурыч бездә ел буе җитештерелгәннән 6 процентка артып киткән. Байден, бу әҗәтне кичереп, сайлаучылар мәхәббәтен яуларга тели. Шуның кадәр әҗәттән коткарса, халык үз Президентын ныграк ярата башларга мөмкин, әлбәттә. Әмма бу АКШта һәм бөтен дөньяда инфляциянең яңа бөтерелүен вәгъдә итә. Димәк, АКШ студентлары җыйган бурычны бөтен планета белән бергәләп түләргә туры киләчәк.

Россиядә

КӨНБАТЫШКА ВИЗА ЮК, АЛТЫННЫ КЫТАЙГА САТАБЫЗ

Федераль хөкүмәт газетасының дүшәмбе саны, Европа Берлеге илләренең тышкы эшләр министрлары алдагы атнадан Россия белән визалар турында килешүне туктатып торырга ниятлиләр, дигән хәбәр урнаштырган. Соңгы атналарда визалар мәсьәләсе, чынлап та, бик кискенләште, мәгълүмат кырындагы кайнар темага әверелде.

Россиянең ут күршеләре – Көнбатышта аңа терәлеп торган илләр Көнчыгыш күршеләрен үзләренә килүдән тыю турында беренче булып чәчрәп чыкты. Эш шуңа барып җитте: хәтта инде үзләрендә рөхсәт алып яшәп ятучы россиялеләрне дә яшәү хокукыннан (вид на жительство) мәхрүм итү һәм визаларын гамәлдән чыгару турында шаулаучы илләр барлыкка килде. Вәләкин ул шаукымга Европаның иң куәтле һәм дәрәҗәле илләре кушылып ук бетмәде. Франция һәм Германия «Россия Хөкүмәте белән бәйләнеше булмаган»нарга виза бирүне дәвам итүне яклады. Оппозиционер икәнсең, Көнбатыш капка синең өчен ябылмый ягъни.

Таяк ике башлы бит. Әле санкцияләр көсәгенең үз башларына төшүеннән дә айный алмаган илләр байтак. Тимер пәрдә аша чыкканда, «махсус хәрби операция»не якламавың турында имза салып кына чыгу мөмкинлеген кертергә теләгән илләр бар. Бу соңгы чарага Мәскәүдәге җете патриот сәясәтчеләрнең аеруча каны кыза. Андый документка имза салучыларны Россия гражданлыгыннан мәхрүм итү идеясен байрак итеп селтәгән сәясәтчеләр күренә. Патриотларның визасыз калу ихтималлыгына кызыл чүпрәккә ташланган үгез кебек котырып ябышулары бик аңлашылып ук та җитми. Дөрес, аларның күбесенең күчемсез милеге, банк хисаплары Көнбатышта. Нәрсәгә гади кешегә Көнбатыш? Азия – Африка илләре, Якын Көнчыгыш безне үзләренә бик теләп кертә, шулай булгач, ял итәсең киләме, эшкә сусадыңмы, шул өченче дөнья илләренең һавасы менә дигән бит инде. Дөрес, әле яңа гына Польшадан кайтучылар андагы азык-төлекнең арзанлыгына тел шартлатты шартлатуын.

Көнбатыш белән пар чыгарып талашуыбыз – дус илләр файдасына. Әллә никадәр дивидендлар алалар шул конфликттан. Кытайга ташкүмер ярты бәясеннән китә. Россия нефтен утыз процентлык дисконт белән (арзанайтып) этеп кертергә тырышабыз. Европада безнең «кара алтын»га эмбарго срогы якынлашкан саен, дисконт күләме артырга да ихтимал. «Кара алтын» гына түгел, ялтырап торган чып-чын Россия алтыны да бик шәп үтә дус илләргә. Кытай июль аенда Россиядән алтын импортлауны июнь белән чагыштырганда 8,6 тапкыр арттырган. Ә үткән елның июле белән чагыштырганда арту 50 тапкыр. Моңарчы алтынны Бөекбритания күпләп алган булса (безнең экспортның 84 проценты), хәзер Россия алтынын британнар яратмый башлаган. Германия, Франция, Италия кебек илләр дә, безгә үч итеп, алтынсыз калалар. Хәтта нейтраль Швейцария дә аннан баш тартты. Ә менә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Кытайдан калышмаска тырышып, алтынга тиенә. Алтын экспортының бәясе әйтелми, яшерен. Тик шулай да белгечләр, дисконт 30 процент тирәсе, диләр.

Киләчәкне уйлап

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Нәтиҗәле булсын

Кичә исә Ратушада Яшьләр глобаль саммитының пленар утырышы узды. Искәртеп үтик: әлеге чараны Казан Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы статусында кабул итте. Казанга 67 илдән 300ләп кунак килде. Алар арасында Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең консуллары, яшьләр оешмалары лидерлары, яшьләр сәясәте тармагы вәкилләре, фән белгечләре, министрлар, гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчеләр бар.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, утырышта күтәрелгән сораулар актуаль яңгыраш таба. Яшьләр мөмкинлекләргә, гаделлеккә, тигезлеккә сусаган буын санала. Алар өчен халыкара аралашу да мөһим. «Россия мисалында без яшьләрнең милләтара татулык, дин һәм халыкара хезмәттәшлек өчен җан атуларын күрәбез. Шул ук вакытта республика Россиянең бердәмлек һәм татулыкны күрсәткән иң тотрыклы төбәкләренең берсе булды һәм шулай булып кала да», – диде республика җитәкчесе.

Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, теләсә кайсы җәмгыятьнең бурычы – яшьләргә аның сәләтен ачу, тормышка ашыру, җәмгыять тормышында катнашу өчен мөмкинлек, сыйфатлы белем бирү. Бу җәһәттән республикада яшьләр белән эшләүгә игътибар зур.

– 14 яшьтән алып 35 яшькә кадәр булган яшьләр саны Татарстан халкының 28 процентын тәшкил итә. Без үз эшебездә заманча яшьләр мәдәниятенә кирәкле ярдәм күрсәтергә, яшьләрнең социаль, икътисади, сәяси активлыгын үстерү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне кулланырга тырышабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Пленар утырышта чыгыш ясаучыларны фикер уртаклыгы берләштергәне күренә. Һәркем үз илендәге тәҗрибәсе белән уртаклашты, тәкъдимнәрен җиткерде. Яшьләр тармагына кертемнәрне җәлләмәскә кирәк – төп нәтиҗәсе дә шул булгандыр. Чөнки бу киләчәктә җимешен бирәчәк. Икътисади тел белән әйткәндә, иң кыйммәтле актив та – яшь кадрлар. Бүгенге яшьләр – иртәгәге дөньяны ясаучылар бит.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Рәсми хәбәрләр

Президент Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә Бөтендөнья этноспорт конфедерациясе президенты Билал Әрдоган белән очрашты. Ул Татарстанга «Казан – Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы» чаралары кысасында узучы Казан Яшьләр глобаль саммитында катнашу өчен килде.

Рөстәм Миңнеханов Төркия Президенты Рәҗиб Тайип Әрдоганга Татарстан – Төркия хезмәттәшлеген үстерүдә ярдәме өчен рәхмәт белдерде. «Аның шәхси ярдәме белән безнең мөнәсәбәтләр ныгый», – диде Президент һәм икътисади элемтәләрне үстерүдәге өлеше өчен Төркиянең Казандагы консуллыгын аерым билгеләп үтте.

Ул Билал Әрдоганның, Бөтендөнья этноспорт конфедерациясе президенты буларак, төрле халыклар, шул исәптән төрки телле дәүләтләр арасында мәдәни һәм спорт элемтәләрен үстерү өчен күп эш башкаруын билгеләп үтте. Татарстан Президенты Халыкара көрәш федерациясен конфедерациягә керткән өчен рәхмәт белдерде.

Үз чиратында Билал Әрдоган әтисе – Төркия Республикасы Президенты Рәҗиб Тайип Әрдоган исеменнән җылы сүзләр җиткерде. «Чакыруыгыз өчен бик зур рәхмәт, Казанның ИХО яшьләр башкаласы дип игълан ителүе безнең өчен шатлыклы хәбәр булды, – диде кунак. – Без – татарлар белән тугандаш халыклар. Без һәрвакыт сезгә ярдәм итеп торачакбыз».

***

Президент Рөстәм Миңнеханов Гагаузия (Молдова) автономияле-территориаль берәмлеге башлыгы Ирина Влах белән очрашты.

Яклар Татарстан һәм Гагаузия арасында хезмәттәшлекне ныгыту, шул исәптән сәүдә-икътисади элемтәләрне үстерү, агросәнәгать секторында, медицинада, IT өлкәсендә хезмәттәшлек итү, алга таба делегацияләр алмашу һәм уртак мәдәни проектларны гамәлгә ашыру турында фикер алыштылар.

Ирина Влах белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да очрашты. «Татарстан белән безнең бик җылы мөнәсәбәтләр урнашты. Безнең Татарстан белән килешүгә 1999 елда ук кул куелган иде. Шушы чордан бирле мөнәсәбәтләр елдан-ел яхшырды һәм без уртак төбәкара проектлар тормышка ашырдык. Без бу тәҗрибәне өйрәнәбез һәм безнең төбәктә кулланырга тырышабыз. Ике арадагы хезмәттәшлек регионыбыз икътисадына, тулаем хезмәттәшлеккә уңай йогынты ясый», – диде Ирина Влах.

ТАТУЛЫКНЫҢ АРТЫГЫ ЮК

Сездән башка булмый. Милли матбугат чаралары форумында Фәрит Мөхәммәтшин журналистларга әнә шулай диде. Бу юлы каләм һәм микрофон әһелләренең туган телләрне, рухи һәм мәдәни мирасны саклап калуда зур эш башкаруы, тагынниләр эшләргә кирәклеге турында сөйләштеләр.

Россиянең 30 төбәгеннән килгән журналистларны бер урында очраштырган форум 29–30 август көннәрендә Татарстанда уза. Исеменнән күренгәнчә, форум милли һәм төбәк матбугат чараларының бүгенге хәленә бәя бирү, аларның үсеш юлларын ачыклау, борчыган мәсьәләләр турында уртага салып сөйләшү, тәҗрибә уртаклашу кебек максат-бурычларга юнәлтелгән.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин инде IX мәртәбә уздырылган әлеге җыенның ихтыяҗы һәм әһәмияте зур булуын искәртте.

– Шушы еллар дәвамында төрле милләт һәм диннәр арасындагы тату мөнәсәбәтләрне популярлаштыру өлкәсендә фикер алышу һәм тәҗрибә алмашу өчен яхшы мәйданчык булдырылды. Төбәк һәм милли матбугат чаралары мәдәниятара диалогта мөһим канал булып тора, шактый катлаулы теманы – милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне яктырта. Милли тәңгәллекне, телләрне, рухи-мәдәни мирасны ныгытуда да журналистларның роле бик зур, – диде ул форумның пленар утырышында.

Шуннан соң «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев Фәрит Мөхәммәтшинга «Бәллүр каләм» бәйгесенең «Ел медиа-шәхесе» номинациясендә җиңүче дипломын тапшырды.

Дәүләт Советы Рәисе Татарстанның милләтләр һәм диннәр арасындагы дус-тату мөнәсәбәтләр үрнәге булуын да әйтте. Моның белән Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисе Геннадий Семигин да килеште һәм башка төбәкләрдәге матбугат чараларына Татарстандагы тәҗрибәне үзләрендә дә кулланырга өндәде.

– Милли сәясәтне гамәлгә ашыруда Татарстан – алдынгы урында. Монда җитәкчеләр барлык халыкларның мәдәниятен, телләрен һәм традицияләрен үстерү өчен иң уңай шартлар тудырып кына калмыйча, булган проблемалар турында сөйләшергә дә курыкмый. Ә бит җитәкчеләр арасында милләтара мәсьәләләрне бары тик милли республикалар проблемасы дип санаучылар да бар, – диде ул.

Геннадий Семигин Россиядә милли сәясәтне яңартырга һәм аны гамәлгә ашыруны җайга салырга кирәклеген дә әйтте. Аның сүзләренчә, бүген нәрсә эшләргә кирәклеген беләбез, тик киләчәкне уйлап җиткермибез.

«Этносара журналистика гильдиясе» иҗтимагый оешмасы президенты Маргарита Лянге милли һәм төбәк матбугат чараларының проблемаларына тукталды. Басма матбугатның «авырткан» урыннары күбрәк булгач, күбрәк газета-журналлар телгә алынды.

– Беренчедән, аларның аудиториясе кими. Кызганыч, бүгенге яшьләр традицион матбугат чараларын укырга атлыгып тормый. Әйе, бүген милли һәм төбәк матбугат чараларына дәүләт тарафыннан ярдәм аз күрсәтелми. Ләкин кайбер матбугат чаралары моны тиеш нәрсә кебек кабул итә һәм бернинди дә көч куймый. Укучыларының саны кимүдә үзләрендә гаеп күрмиләр. Без мөмкинлекләр чорында яшибез, шуңа да журналистларга яңа форматлардан курыкмаска киңәш итәм, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика парламентында Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисе Геннадий Семигин белән очрашты. Геннадий Семигин фикеренчә, Татарстан өч дистә ел эчендә конструктив диалог моделен эшләп чыгара алды, бу республиканың горурлыгы һәм визит карточкасы булып тора. Ул Татарстан Халыклар ассамблеясы һәм Татарстан халыклары дуслыгы йорты эшенә югары бәя бирде. Татарстанга сәфәре нәтиҗәләрен шәрехләп, ул республиканы милләтара мөнәсәбәтләр, мәдәниятне, этнокультураны үстерү буенча башкаларга үрнәк дип атады. «Милли республикалар гына түгел, Россия Федерациясенең башка субъектларына да үрнәк алырга кирәк. Мин моны барлык губернаторларга киңәш итәчәкмен. Без дә кайбер кызыклы нәрсәләрне алачакбыз, ә аннары парламентка кертеләсе закон проектларында тормышка ашырачакбыз», – диде ул.

ЯКТЫ РУХЛЫ БӘЙРӘМ

Бөтенроссия «Белем көне» бәйрәме уңаеннан Татарстан Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле укытучылар, мөгаллимнәр, мәгариф өлкәсе хезмәткәрләре!

Барлык укучыларны, урта һәм югары уку йортлары студентларын, педагогик җәмәгатьчелек вәкилләрен – укытучылар һәм тәрбиячеләрне, тренерларны, Татарстан мәгариф системасы хезмәткәрләрен, ветераннарын күтәренке һәм якты рухлы бәйрәм – Белем көне уңаеннан ихлас котлыйм.

Төрле тарихи чорларда, данлыклы җиңүләр яуланган яисә авыр сынаулар кичергән вакытларда яңа уку елы башланган көнне – 1 сентябрьне без һәрчак гомумдәүләт дәрәҗәсендәге зур вакыйга, буыннар арасындагы ныклы бәйләнеш, күпмилләтле халкыбызның мәгърифәткә һәм яңадан-яңа фәнни ачышларга булган көчле омтылышының чагылышы буларак кабул итәбез.

Барлык милләт һәм дин вәкилләренә, олысына-кечесенә бердәй якын һәм аңлаешлы булганлыктан, Белем көне Россиядәге сыман тантаналы һәм киң колачлы итеп дөньяның бер генә илендә дә бәйрәм ителмидер, мөгаен. Әмма шулай да, иң әүвәл бу – дулкынланып тәүге кат мәктәп бусагасын атлап кергән, якты хатирә булып күңелләрендә гомергә сакланачак беренче укытучылары белән очрашкан-танышкан беренче сыйныф укучыларының бәйрәме. Бөек илебезнең киләчәге турыдан-туры яшь буынның ни дәрәҗәдә белемле, мәдәниятле, иркле, җаваплы һәм нык фикерле булып үсүенә бәйләнгән.

Һәрбер җәмгыятьнең үсеше нигезен сыйфатлы, конкурентлыкка сәләтле, матди-техник базасы тотрыклы булган мәгариф тәшкил итә. Хәзерге замандагы сәяси вазгыять, читтән бертуктаусыз илебезгә, шул исәптән мәгарифкә һәм фән өлкәсенә ясалган басым уртак тырышлык куюны, үз мөмкинлекләребез һәм традицияләребезгә таянуны таләп итә. «Мәгариф» илкүләм проектын, хәзерге заман мәктәбен камилләштерүне һәм цифрлы нигезгә корылган белем бирү программасын уңышлы гамәлгә ашыру, фәнне югары технологияле, чит илләрнекен алмаштыра алырдай продукция җитештерүгә юнәлтү безгә күркәм нәтиҗәләргә ирешү өчен юллар ачар дип ышанам. Татарстанда Цифрлаштыру елында уздырыла торган чаралар моңа зур этәргеч бирергә тиеш.

Татарстан педагогларына, югары уку йортлары мөгаллимнәренә, профессорларга, мәгариф өлкәсендә эшләүче һәркемгә олы рәхмәтемне белдереп, республика җитәкчелеге җәмгыятебез өчен гаять мөһим хезмәтегездә киләчәктә дә барлык кирәкле шартларны тудырачак дип ышандырасым килә. Сез яшьләребез күңеленә сеңдерә, тәрбияли килгән Ватанга мәхәббәт, туган телгә хөрмәт кебек рухи хәзинәләр, тырышлык, намус белән эшләү, гыйлемгә омтылу кебек сыйфатлар, файдалы гамәли күнекмәләр әһәмиятен һичкайчан җуймый.

Сезгә, кадерле дуслар, чын йөрәктән яшәү дәрте, иминлек, сәламәтлек, белем бирү, фән өлкәсендә яңа казанышларга ирешүегезне телим!

Белем көне мөбарәк булсын!

ИКЕ ГАИЛӘ – БЕР БИЗНЕС

Минзәлә

Туган авылларында калып, үзләрен һәм гаиләләрен эшле иткән кешеләргә соклануым һәрвакыт зур булды. Алар яшьләр дә булса, куанычым икеләтә арта. Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче бертуган Илдар һәм Илгиз Мәүзиевләр белән аралашып сөйләшкәч тә, шундый ук хисләр кичердем. Алар, бер ел элек авылда цех ачып, балалар өчен җиһазлар ясый башлаган.

Әлеге авылга баргач, Илгизне күреп сөйләшә алдык. Аның әйтүенчә, егетләр бу эшкә ничек кереп китүләрен үзләре дә сизми калган.

– Безнең эшчәнлегебез халык ихтыяҗыннан башланды. Башта балаларга урамда яки өйдә эленә торган атынгыч ясаган идек. Берничәне эшләп карау белән үк башка төр җиһазларга заказлар ала башладык. Шулай итеп, акрынлап балалар өчен өстәл һәм урындык сораучылар артты, – диде ул.

Бераздан егетләр үзмәшгуль буларак теркәлгәннәр, цех ачып җибәргәннәр. Алга таба да эшләрен җәелдереп, йомшак җиһазлар җитештермәкче булалар.

– Башта барлык эшне дә кул белән башкардык. Авыр да, мәшәкате дә зур булгач, заказларны эшләү озакка сузыла иде. Кешеләрне көттерү дә уңайсыз булды. Аннан соң заманча станокларга күчтек. Эшләр күпкә җиңеләйде, әлбәттә. Ләкин шулай да кул эшен тулысынча бетереп булмый. Җиһазларга кул көче дә күп кирә. Аның караву хәзер кайбер җиһазларны алдан да ясап кую мөмкинлеге артты, – ди ул.

Заказлар дигәннән, аларның бетеп торганы юк икән. Республика халкы балалар җиһазларын яратып алса да, Илгиз әйтүенчә, күпчелек клиентлары – Мәскәү якларыннан.

– Чаллы якын булгач, шәһәрдә безне белүчеләр күп. Аннан, гадәттә, урындык-өстәлләргә күп заказлар килә. Мәскәүлеләр исә бизәнә торган өстәлләр ала. Бер заказ Дубайга да китте. Сочиның бер балалар бакчасында тулысынча без ясаган җиһазларны күрү – үзе бер куаныч. Кайбер әти-әниләр балалар бүлмәсен шулай ук тулысынча җиһазлап бирүне сорый, – ди Илгиз Мәүзиев.

Шулай булмыйни, кайсы гына әти-әни баласының бүлмәсен затлы, купшы итеп бизәргә, җиһазларга теләми икән? Балалар бүлмәсенә өстәл, урындыклар, шкафлар, бизәнү өстәле, кием элгечләре ясый егетләр.

– Иң еш сорала торган җиһазыбыз – бизәнү өстәле. Карап торышка мәшәкатьсез эш кебек тоелса да, вак-төяк эше күп аның. Үзебезнең дә кызларыбыз үсеп килә. Шуңа күрә җиһазларны иң элек алар сынап карый. Димәк, безнең өчен сыйфат – һәрвакыт беренче урында, – дип елмая ул.

Яңа цехта исә йомшак җиһазлар эшләргә дә уйлары бар.

– Әлегә анда урындыклар ясаячакбыз. Бәлки, акрынлап караватлар да эшли башларбыз. Аларны да инде сораучылар бар, – ди һөнәрче егет.

Илгиз әйтүенчә, яшьләрнең төп максаты авылны саклап калу, күңелләренә хуш килгән эш табу булган.

– Безнең бурыч әлеге җиһазларны ясап сату гына түгел. Ә үзебезне, гаиләләребезне эшле дә, ашлы да итү. Киләчәктә авылдашларыбызга да эш урыны булсын дип телибез, – ди Илгиз. – Хәзер кешегә төпле эш урыны кирәк. Сез авыл мәктәпләрен күрегез әле. Нинди генә программаларда катнашмый да алар, ничек кенә матурламыйлар белем йортларын. Бүген безнең мәктәптә 55 бала укый. Ә минем хыялым – шул мәктәпнең гөрләп торуын күрү. Авылга кеше кайтсын иде. Безгә дә тагын бер авылдашыбыз ярдәм итә.

Әлеге ике яшь гаилә бер яктан тырышлык, тәвәккәллек үрнәге булса, икенче яктан туганлык җепләрен саклаулары белән дә хөрмәткә лаек.

– Туганым белән яшь аермабыз зур түгел, – дип елмая Илгиз. – Нибары 1,1 яшь кенә. Мәктәпкә дә бергә бирделәр безне. Институтта да бергә укыдык. Хәтта армиягә дә бергә барып, бер ротада, бер взводта хезмәт иттек. Шуннан соң икебез бергә Боз сараенда тренер булып эшләдек тә менә хәзер шушы эшебезне алып барабыз. Әле җитмәсә, күршеләр дә без. Туганнан бирле бергә, кыскасы. Шуның белән бәхетле дә без. Туганың белән эшләүнең бер генә кыенлыгы да юк. Киресенчә, уңай моментлары күбрәк. Бер-беребезне хөрмәт итеп, аңлашып эшлибез.

Авыл өчен менә мондый гаиләләр тагын да зуррак куаныч. Югары Тәкермән авыл советы башлыгы Алия Шәрипова да әнә шулай ди:

– Авылыбыз менә шундый егетләребез булу белән бәхетле. Алар спорт белән дә шөгыльләнә. Минзәләдә хоккей буенча тренер алар. Бер генә спорт чарасы да алардан башка узмый. Ә һөнәргә килгәндә, безнең авыл халкы элек-электән шөгыльле булган. Бабайлар, ачлык заманында да безнең халык хәер сорашмады, дип әйтәләр иде. Ул елларда да авыл халкы чабата үреп көн күргән.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕР МАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ӨСТӘМӘ САЙЛАУГА ТЕРКӘЛГӘН КАНДИДАТЛАРНЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

МАТЕРИАЛЛАР АВТОР ӘШКӘРТҮЕНДӘ БАСТЫРЫЛА. АЛАРНЫ ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ УРНАШТЫРУ БАСМА МӘЙДАН БҮЛҮ БУЕНЧА ҮТКӘРЕЛГӘН ЖИРӘБӘ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

№ 7 Ибраһимов
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Мөхәммәдшина Р.Җ.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 14 Пионер
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Гарипов Р.Ә.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 7 Ибраһимов
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Галимҗанов Р.А.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 7 Ибраһимов
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Ниязов Р.И.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

2022 елның 26 августы, N 179/1574
Казан ш.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавышка ия әгъзасы итеп билгеләү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителә торган кандидатура турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләре срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашуга хокукларының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы 5 пунктына, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы 5 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавышка ия әгъзасы итеп, Надежда Петровна Борисованы (1962 елда туган, белеме – югары юридик, юридик фәннәр кандидаты, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаре) билгеләүне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.
3. Бу карарны «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.
4. Бу карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе рәисе А.С. Кондратьев
Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе секретаре Н.П. Борисова

ЮЛ БАШЫ

«Татарстан» журналы/Лилиана Вәлитова

Арча

Арча районына очрашуга чакырганнар иде. Педагогия көллиятендә урнашкан Әлифба музее (аның тулы исеме – Дөнья халыкларының букваристика һәм әлифба сәнгате музее) белән танышу да көн тәртибенә кертелгән. Яңа уку елы алдыннан бу гамәл бигрәк тә урынлы булып чыкты. Һәр кеше үзе укыган китапны күреп, сөенә-сөенә, балачак эзләрен барлады.

Мин үзем дә бу музейда беренче тапкыр гына түгел. Караган саен карыйсы килә дип, әнә шундый җанга рәхәт әйберләр турында әйтәләрдер, күрәсең. Гөр килеп, «Алсу су ала»ларны укып йөргәндә, музей җитәкчесе Дамир Таҗиев безне үз янына чакырып алды: «Кайсыгыз гарәп шрифтын белә? Монда нәрсә дип язылган?» – дип сорады. «Юл башы» дигән сүзләр укыдык. Баксаң, Сөләйман Хәлиуллин дигән автор үзе иҗат иткән әлифбага әнә шундый исем биргән икән.

Ни өчен бу музей нәкъ менә Арчада ачылган? Иң элек барысын да шушы сорау кызыксындырды.

– Бик күпләр аны Тукай белән бәйләп карыйлар, – диде Дамир Таҗиев. – Монысын да бөтенләй инкарь итеп булмый инде. Бөек шагыйребезнең туган җире бит. Ә менә 60 ел буена балаларны белемле иткән Әлифбаның да туган җире Арча икәнен күпләр белеп бетерми әле. Бу дәреслекнең авторлары – Арча көллиятендә татар теле һәм әдәбиятыннан белем биргән Сәләй Вагыйзов белән Рәмзия Вәлитова. 1999 елда бу музей алар хөрмәтенә ачыла да инде. Тарихы болайрак. 1998 елда Сәләй агага – 90, Рәмзия апага 85 яшь тула. Көллияттә уздырылган юбилейга ул вакыттагы Татарстан мәгариф һәм фән министры Фариз Харисов килә. Аның чыгышында шундый бер җөмлә була: «Мондый кешеләргә музей ачарга кирәк!» Министр шул көнне Казанга кайтып китә, ә икенче көнне әле генә 60 яшен тутырып лаеклы ялга чыккан тарих укытучысы Хөсәен Хәйруллин көллият директоры Илдус Сәгъдиев янына керә. Җитәкчедән фатиха алгач, җиң сызганып эшкә тотына. Бер ел эчендә кирәкле экспонатлар җыела, концепция төзелә һәм 1999 елның 6 октябрендә музей тантаналы төстә ачыла.

Музей өч залдан тора. Хуҗаны тыңлыйтыңлый, беренчесенә – дөнья халыклары әлифбалары бүлегенә керәбез.

– Әлифба музее ачылгач, ул тагын бер юнәлешне үз эченә алып китә, – дип сүзен дәвам итә Дамир Таҗиев. – Дөнья халыкларының әлифбаларын җыя башлый. Беренче 20 дәреслекне Сәләй ага белән Рәмзия Вәлитова тапшыра. Аннан музей хезмәткәрләре, әлифба сорап, башка республикаларга хатлар язалар. Студентлар, укытучылар барган бер җирдән әлифба күтәреп кайталар. Хәзер монда сигез экспозициягә 160 әлифба куелган, алар – дөньяның 72 телендә.

Икенче бүлектә исә Татар әлифбасы һәм татар язуы турында мәгълүматлар. Белгәнебезчә, без кириллица белән 1939 елда гына яза башлаганбыз. Аңа кадәр ун ел латин хәрефләрен кулланганбыз. Ә мең еллык тарихыбыз гарәп графикасына бәйле. Бу җәһәттән профессор Мөхетдин Корбангалиевнең эшчәнлеге бик кызыклы. Ул шундый чорга эләгә: әлифбаны өч графика белән дә төзергә туры килә.

Өченче залда Сәләй ага белән Рәмзия апа эшләренә урын бирелгән. Ул үзе дә нәкъ шулай «Сәләй Вагыйзов белән Рәмзия Вәлитова залы» дип атала.

– Бу залда мең ярымнан артык экспонат әлифба темасын төрле яклап яктырта. Иң кадерлеләре – авторларның эскизлары, каралама битләре. Алар өч папкага туплап куелган. Үзебезнекен төзи башлаганчы, бу мөгаллимнәр 20 милләт халкының дәреслекләрен өйрәнәләр. Аларның иң яхшы якларын үзләштереп, татарча әлифбаны балалар тиз укый-язарга өйрәнерлек итеп төзиләр. 1965 елда дәреслек басылып чыга. 50 ел эчендә ул 42 тапкыр нәшер ителә, өч тапкыр үзгәртелә, тиражы бер миллион данәгә җитә.

Әлбәттә инде, бу шәхесләрнең язмышы белән кызыксынучылар да күп булды.

– Әлифба авторлары бик озын гомер яшәделәр. Сәләй ага – 96, Рәмзия апа 88 яшькә җитеп дөнья куйдылар. Ә аларның язмышлары, чыннан да, Тукайныкына охшаш. Икесе дә – дөм ятимнәр. Сәләй аганы үз авылында – Самара өлкәсендәге Камышлы районының Татар Байтуганы авылында асрамага алалар, Рәмзия апа балалар йортында үсә. Казан педагогия институтында танышалар, соңгы курста укыганда өйләнешәләр. Юллама буенча Арча педагогия училищесына киләләр. Бу 1937 ел була. Кызлары Римма белән уллары Камил туа. Сугыш башлангач, Сәләй фронтка китә, бер елдан әсирлеккә эләгә. Исән-сау котылганнан соң, аны ун елга Печора лагерьларына җибәрәләр. Хатыны, балаларын алып, ике җәй рәттән аның янына бара. Беренче баруы әйбәт кенә уза, әмма икенчесендә аны күңелсез хәлләр көтеп тора. Ел саен сатлыкҗан янына йөри дип, кемдер шикаять яза. Рәмзия апаны фатирдан чыгаралар, эшеннән куалар. Ул ике бала белән урамда кала. Ире аңа мондый хат җибәрә: «Рәмзия, син миннән ваз кич. Балаларны үстерәсе бар, шулай яхшырак булыр», – ди. Хатыны шулай эшли, әмма бары тик балалар хакына гына. Тормыш, чыннан да, бераз җайлана төшә. Ун елдан соң Сәләй ага Арчага кайта, педучилищега эшкә алмыйлар, төрле авыр эшләрдә йөри. Тормышында борылышны үзенең укучысы, ул вакыттагы район мәгариф бүлеге мөдире Равил Галиәхмәтов ясый. Ул аңа уку йортына кайтырга мөмкинлек тудыра.

Бүген Әлифба музее – татар телен саклау, үстерү, кулланыш даирәсен киңәйтү юнәлешендә эшләүче үзәкләрнең берсе. Ул дөньяда бердәнбер булуы белән уникаль. Сабыйлар өчен генә түгел бу музей, министрлар, депутатлардан башлап, укытучылар, табиблар, гомумән, барлык һөнәр ияләре дә килә монда. Әлифба һәр кеше өчен кадерле. Ул – әти-әни, беренче мәхәббәт, беренче укытучы кебек кыйммәтле төшенчә. Әлифба укыган кеше татар телен гомер буена онытмый.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе киңәшчесе **Васильев** Валерий Павлович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Милли көрәшне популярлаштыруга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны, «Чаллы шәһәре көрәш федерациясе» җирле иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Хәмитов** Рәкыйп Хатип улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләргә.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тоту бүлеге мөдире **Абрашкин** Павел Владимирович; актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлекләре өчен Казан шәһәр Думасы депутаты, «Барысы да балаларга» сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларның һәм яшүсмерләрнең гармонияле үсеше буенча автоном коммерциячел булмаган хәйрия оешмасын гамәлгә куючы **Гайнанова** Далия Илгиз кызы; «Өмет» территориясе советы» территориаль иҗтимагый үзидарәсе рәисе, Чаллы шәһәре Автозавод районының территориаль иҗтимагый үзидарәләрне үстерүгә булышлык итү ассоциациясе идарәсе рәисе **Наумкина** Венера Михайловна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе **Гафаров** Рөстәм Гыйльфан улы; Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының сугыш һәм хезмәт ветераннары җирле иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы **Жаркова** Зинаида Петровна; Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасының өстәмә белем бирү педагогы, «ЯШЬ АРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирле бүлекчәсе штаб башлыгы **Җиһаншин** Ринат Сөббух улы; «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте Эшләр идарәсе инспекторы (ветераннар белән эшләү буенча) **Филинова** Фиалка Мөдәррис кызы; Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Хәмзин** Рафис Рафик улы; Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасының «Буа дәүләт драма театры» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе – директоры **Садриев** Раил Илдар улы; Татарстан Республикасы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлегенең «Мәдәни-мәгърифәти эш үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Солдатова** Марина Михайловна; Петербургның музыка әһелләре берлеге рәисе **Шакиров** Ринат Сәгыйть улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, III–IV чакырылыш (2004–2014 еллар) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты

Александр Сергеевич ЕВДОКИМОВның

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Сезнең белән бергә кайгырабыз һәм кире кайтарып булмаслык югалту ачысын бүлешәбез.

Белдерү

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәр

Түбәндәге территориядә урнашкан күчемсез милек объектларына карата 24.05.2022 ел, № 9222000153-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Колай авыл җирлеге, кадастр кварталлары номерлары 16:33:051604, 16:33:051606;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге, кадастр кварталы номеры 16:33:100908;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, кадастр кварталы номеры 16:33:080515;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шәле авыл җирлеге, кадастр кварталы номеры 16:33:170423.

Мәнфәгатьле барлык затларга территорияләрнең карта-планы проектларын әзерләүнең төгәлләнүе турында хәбәр итәбез. Алар белән килештерү комиссияләренең эш адреслары буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай ав., Профсоюз ур., 24а й. (телефон: (8-84367) 36-5-25, 36-5-80);

Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Ленино-Кокушкино ав., Үзәк ур., 17 й. (телефон: (8-84367) 3-40-24);

Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково ав., Комсомол ур., 13 й. (телефон: (8-84367) 40-1-81);

Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле ав., Хәйруллин ур., 35 й. (телефон: (8-84367) 2-51-46)яки Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының – https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органының – https://pestreci.tatarstan.ru.);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (кадастр учеты органының – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында танышырга мөмкин.

Аларга карата 16:33:051604, 16:33:051606, 16:33:100908, 16:33:080515, 16:33:170423 кадастр кварталлары территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2022 елның 15 сентябрендә 11 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., Совет ур., 18 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2022 елның 26 августыннан 2022 елның 15 сентябренә кадәр һәм 2022 елның 15 сентябреннән 2022 елның 19 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шул исәптән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон почтасы адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә шушы каршы килүне җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдырганда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән) документлар (булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Яшәеш

БЕР ЯҢГЫР ҖИТМӘДЕ

Бу көннәрдә бәрәңге кабат авыл халкының теленә менде: ике кеше очрашса, бер-берсеннән: «Бәрәңге казымадыгызмы әле?» – дип сорашмый калмый. Аннан инде, шулар сабагын чапкан, болар казыткан, дип, авыл хәлләрен сөйләү, таныш-белешләрне сорашу китә. Бу аңлашыла да: елның-елында август азагында, балалар – мәктәпкә, студентлар калага киткәнче дип, бөтен кеше, мәш килеп, бәрәңге ала торган иде.

Быелның язы-җәе үзенчәлеклерәк булганга, бу көннәрдә авыл халкы аптырашта әле: казыргамы бәрәңгене, көтәргәме? Бу эсседә җир астында торса уңайракмы, җыйнап алып, базларга салу файдалыракмы? Гомер булмаганны, май азагы – июнь башында бәрәңге утыртканнар исә, бәрәңге өлгерергә кирәкле көне тулып җитмәде бит әле, дип икеләнә. Тик көне тулган-тулмаганга карамый, табигать үзенекен итә: күп кешенең бакчасында бәрәңге сабагы тәмам корып бетте инде.

Авылда бәрәңге алучылар әлегә бармак белән генә санарлык. «Искиткеч күп яралган, их, бер яңгыр җитмәде, үсеп бетә алмаганнар», «Ашарга җитәрлек бәрәңге булды, елына күрә шөкер итәрлек», – диючеләр дә, басулары дымлырак урында булганнар яки инеш-бөяләрдән су сиптерүчеләр арасында: «Елдагы бәрәңгене җыйдык», – дип әйтүчеләр дә бар.

– Түбән очлар бәрәңге алган. Андагы кәсәнкене күрсәгез! Һич алдаусыз, ярты өстәл зурлыгындагылары бар. Аның арасыннан ничек бәрәңге чүпләделәр икән, анда йөри торган түгел, – ди бер авылдаш.

– Казыгычлар ничек чыдады икән, без өлгереп алдырганчы, алар ватылып бетмәсә ярый, – дим (авылда хәзер беркем дә көрәк-сәнәк белән бәрәңге казымый, ян бакчаларны да трактор белән алдырабыз).

– Мин дә ул кантар-кәсәнке ничекләр казыгыч рамына сыйды икән дип аптырадым, – ди ул да.

Дөрес шикләнгәнбез икән. Бу авыр эштән бик күпләрне коткаручы, шәхси тракторы булган авылдаш та: «Бер-ике бакча алдыруга, бөтен копалкам эштән чыгып, таралып бетте», – дигән.

– Бер елны да бакчада калган бәрәңге юк әле, – ди күпләр, бәрәңге казу турында сүз чыккач. – Ашыкмыйбыз әле. Яңгырлар явып, җир бераз йомшарып китсен. Элек әнә ничә бакчаны көрәк белән казып-чүпләп ала идек. Хәзер бакчалар кечкенә, берничә сәгатьлек эш инде ул…

…Менә шундый хәлләр. Язын бәрәңге утыртырга көннәр аязганын, яңгырлар туктаганын көтә-көтә көтек булган идек, җәен бәрәңге чәчәк атканнан бирле: «Их, бәрәңгеләргә яңгырның иң кирәк чагы, бер генә яуса да ярар иде», – дидек. Казыр вакыт җиткәч тә, башка елларны көннәр коры торганда дип ашыга идек, быел анысы да киресенчә булырга охшап тора. Бер яңгыр яуса иде, дибез. Эсселәр кимегәнне көтүчеләр дә бар. «Казыгыч керә алмаган өлешен казырга чыккан идек, көндез бакчада түзә торган түгел, иртәнге-кичке салкын белән генә эшли алдык», – диючеләр дә бар.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Спорт

Бүлештеләр

Казанда «Рубин» белән «КАМАЗ» арасында узган матч 1:1 исәбенә тәмамланды. Стадионда Сабан туе оештырып, Салаватны җырлатып башланган очрашуны 18,5 мең тамашачы карады. Бу – беренче лигада быелгы сезон рекорды. Чаллыдан гына шәһәр мэры Наил Мәһдиев белән ике меңләп кеше килде.

Ике команданың инде 24 ел уйнаганы булмаган. Кайчандыр Татарстанның төп командасы булып нәкъ менә «КАМАЗ» саналды. Әмма 1990 нчы еллардагы финанс авырлыклары аркасында, Чаллыда футболга игътибарны киметергә туры килде. Казанда исә «Рубин»ны күтәрергә тырыштылар. Чаллы футболында әлеге вакыйгаларны бик авыр кичерделәр, шуңа күрә ике команда арасындагы матчка аерым мөнәсәбәт күрсәтүләре гаҗәп тә түгел.

Сезон башланыр алдыннан төп фаворит булып саналган «Рубин» әле һаман көтелгәнчә уйный алмый. «КАМАЗ»ның беренче урында баруын, киресенчә, көтелмәгән хәл дип бәялиләр. Беренче тайм Казан командасының өстенлеге белән узды, нәтиҗәдә исәпне хуҗалар ачты. Очрашуның икенче өлешендә Чаллының туп кертү мөмкинлеге күбрәк булды: өстәмә вакытта алар барыбер үз дигәннәренә ирешә алды. Моның өчен премия дә әлегәчәк үзләренә.

	команда	очко
1	КАМАЗ	17
2	Балтика	14
3	Алания	14
4	**Рубин**	**12**
5	Динамо Махачкала	12
6	Нефтехимик	11
7	Енисей	11
8	Волгарь	11
9	Арсенал Тула	9
10	СКА Хабаровск	8
11	Шинник	8
12	Уфа	8
13	Кубань	7
14	Краснодар-2	7
15	Родина	6
16	Велес	6
17	Волга Ульян	4
18	Акрон	4

rubin-kazan.ru

Газетаның киләсе саны 2 сентябрьдә чыга

ҖЫРЧЫ ИЛСУР САФИН:

«МАКТАГАН ДА, ӘРЛӘГӘН ДӘ КӨЧ БИРӘ»

Илсур Сафинның шәхси архивыннан

Гамьле әңгәмә

Бүген татар музыка сәнгате ни хәлдә? Профессиональ җырчы нинди булырга тиеш? Иҗатыңны киң катлауга ничек җиткерергә? Җырчы, Татарстанның халык артисты Илсур САФИН белән әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Бүген эстрадада җырчыларның ниндие генә юк. Сезнеңчә, кем ул профессиональ җырчы – махсус музыкаль белемгә ия кешеме, әллә инде моңга бай, сәнгатькә гашыйк, сәхнәне үз итүчеме?

– Ходайдан сиңа талант бирелгән икән, ул талантны тагын да үстерергә, үз өстеңдә эшләргә кирәк. Җырчы белемле булырга тиеш. Ул тарихны да, әдәбиятны да, үзебезнең татар халык җырларын, классик әсәрләрне, хәзерге заман әсәрләрен дә белергә тиеш. Сәхнәдә үзеңне тоту, тамашачы белән аралашу кебек әйберләрне дә белү мөһим. Укырга, вокалның серләренә төшенергә, яхшы репертуар булдырырга кирәк. Артист үзенең белеме белән халыкны да тәрбияләсен иде.

:: Сезне Татарстанның алтын баритон тавышы, диләр. Шушы дәрәҗәгә ирешү өчен нинди киртәләрне узарга туры килде?

– Мин «алтын» тавышларны – Илһам Шакиров, Рафаэль Сәхабиев, Ренат Ибраһимов, Георг Отс, Мөслим Магомаевны тыңлап үстем. Консерваториядә Әлфия Заһидуллина классында укыдым. Без аны «икенче әнкәй» дип йөртә идек. Иҗат юлына бастырганы өчен, мин аңа бик рәхмәтле. Консерваторияне тәмамлагач, филармониягә эшкә кердем. Анда тагын да репертуар тупладым, татар музыка сәнгатенә төшендем. Тормыш булгач, төрле вакыйгалар булгандыр. Гел турыдан гына бармаган, тайпылулар, абынулар да булгандыр. Мин һәрвакыт үземнең ялгышларны табып, аларны үзем төзәтергә тырыштым. Шул вакытта гына син кеше, чын җырчы була аласың.

:: Татар эстрадасы репертуарын чит ил классикасы белән баеткан җырчыларның берсе дә сез. Репертуарыгызда рус, инглиз, итальян телендәге җырлар бар. Кабул итмәүчеләр, тәнкыйтьләүчеләр булмадымы?

– Барысы да һаман яхшы булып барды дип әйтә алмыйм, булгандыр инде. Тел бетә, дип тә әйтүчеләр булды. Бөтенесе үзебездән тора бит. Тел, дин, рухи байлык булганда, без беркайчан да югалмаячакбыз. Мин концертларны Казанда һәрвакыт ике телдә куйдым. Кабат бер артист та алай эшләмәде. Кызык бит: руслар килеп, татар музыкасын тыңлый. Нинди генә милләт вәкилләре килмәде минем концертларга! Заллар тулы иде. Тәнкыйтьләүчеләр дә, мактаганнар да, әрләгәннәр дә көч бирә. Алар әйтеп торсыннар, без эшли торыйк. Әгәр берни әйтмәсәләр, бер сүз дә яңгырамаса, җыр кызыксыну уятмый дигән сүз бит инде. Аның шунысы начар.

Блиц-сораштыру

– Иң яраткан җырыгыз нинди?
– Мине иҗатымда таныткан «Сөюем бакчасы» җыры.
– Кешедә ачуыгызны чыгара торган сыйфат?
– Икейөзлелек, арттан сөйләп йөрү.
– Иң бәхетле көнегез?
– Улым Русланны алып кайткан көн.
– Бүген нинди максатлар белән яшисез?
– Исән-сау булу. Кеше булып калу, мирас калдыру.
– Тормыш девизыгыз нинди?
– Намуслы һәм дөрес булу.

:: Бүгенге татар музыка сәнгатен ничек бәялисез?

– Музыка сәнгатендә кешенең эчке дөньясы, күңел байлыгы, профессиональлек, эстетика, әхлак, фикер, мәгънә кебек төшенчәләр бетеп бара. Татар эстрадасы зур караңгы күләгә астында кала бирә. Сәхнәдә профессиональлек булырга тиеш. Җырны компьютерда тарттырып, җайлап дөреслиләр дә сәхнәгә чыгып җырлыйлар. Халык әнә шуны тыңлый да. Ә профессионалларны өнәп бетерми, чөнки ул аның тавышын да, эчке дөньясын да аңламый.

:: Алайса, сәхнәдә нинди җырлар яңгырарга тиеш?

– Заман үзгәрә дип, бик җиңеләеп китмик инде. Эстраданың нигезе булып татар халык җырлары торырга тиеш. Бер-ике нотадан гына торган җырлар җырлыйлар хәзер. Төрек стиленә охшатып җырлау модага керде. Үзебезнең татар музыкасы яңгырашы бөтенләй башка бит ул. Безнең үзебезнең йөзебез бар. Халык үзен үзе тәрбияләсен иде. Һаман да сикерешеп-биеп кенә йөреп булмый бит инде. Радио һәм телевидение тәрбия өлкәсендә бик зур роль уйный. Әткәй-әнкәй, илебез, туган нигез турында күбрәк җырлар булсын, сәхнәгә укымышлы кешеләр менсен иде. Хәзерге эстрада – тормышның көзгесе бит.

:: Үз иҗатыңны киң катлауга җиткерү өчен шактый тырышырга кирәк. Аның серләре бармы?

– Хәзер мөмкинлекләр бик күп. Укырга, гел тавыш, тембр белән эшләргә кирәк. Җырчы ул спортчы кебек. Спортчылар аз гына шөгыльләнми торса, шундук формадан чыга. Җырчылар да шулай ук. Ә ул форманы кайтару өчен атналар, айлар кирәк.

:: Сез күп еллар дәвамында Казан мәдәният институтында студентларга вокал дәресләре бирдегез. Сезнең укучыларыгыз популяр җырчылар булдылар. Аларның иҗатын күзәтеп барасызмы?

– Мәдәният институтында 14 ел укыттым. Укучыларымның бөтенесенең үз урыны, тамашачысы бар, Аллага шөкер. Аларның репертуарлары белән танышып, концертларын карап барам. Кайсылары җыр-бию ансамблендә эшли, кайсылары үзләренең коллективлары белән зур шәһәрләрдә, районнарда чыгыш ясыйлар. Мин моңа бик шатланам. 2019 елда Рок мәктәбендә укыта башладым. Анда эшли торган ханымнар, ир-егетләр, 15ләп кеше – укытучылар, табиблар, инженерлар шөгыльләнә. Русча да, татарча да, инглизчә дә җырлыйлар, бик яратып йөриләр.

:: Бер әңгәмәдә, студентларыма мин бик таләпчән, дигәнсез, улыгызга да шундыймы сез? Ул сәхнә юлын сайласа, нәрсә әйтерсез?

– Укучыларыма карата да, улыма да бик таләпчән мин, безне дә шулай тәрбияләделәр бит. Улым Руслан алтынчы сыйныфка бара. Сәхнәдән читтә ул. Тарих, география белән бик кызыксына. Илләр турында, Казан турында күпне белә. Бөтенесенә дә тырыша.

:: Үз гомере буе кеше тәҗрибә туплый, «эчтәлек» җыя. Сезнең – 60 яшькә җиткән, 30 елдан артык иҗат белән яшәүченең эчтәлеге нидән гыйбарәт? Бүгенге тормышыгыздан канәгатьме сез?

– Мин Ходайдан хәзер исәнлек кенә сорыйм. Җыр сәнгатенә килгәнемә, татар халкының зур шәхесләре белән очрашканыма, алар белән сөйләшүемә чиксез шатмын. Яшьлек – бәхет, дип әйтәбез. Мин моның белән килешмим. Бәхет ул – картлыкка җиту, үзеңнең аягында, үзеңнең акылында 70–80гә кадәр яшәү, гаиләң, балаларыңоныкларың булу. Бераз гына мирасым калса бу дөньяда, мине шул да бәхетле итәр.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

САВАПЛЫ СУ

ИМӘНКИСКӘ ҺӘМ СТОЛБИЩЕ ХАЛКЫ «ЧИШМӘ»ЛЕ БУЛДЫ

Лаеш

Күптән көттек! Лаеш районының Имәнкискә авылында һәм Столбище бистәсендә яшәүчеләр суның кадерен башкаларга караганда яхшырак белә. «Чишмә»ле булганнарын белгәч, күз яшьләрен сөрткәләүчеләр шактый булды араларында. Безнең өчен гадәти тоелган нәрсә дә алар өчен хыял булган бит.

Хыялларын чынбарлык иткән кешеләргә рәхмәт укып туймыйлар хәзер. Имәнкискәдә дә, Столбищеда да «Чишмә» дип аталган чиста су алу урыны ачылды. Мондый «Чишмә»ләр Габишево, Усад һәм Сокурыда да бар. Татарстан Иҗтимагый палатасы вәкиле, Тернәкләндерү һәм адаптация үзәге җитәкчесе Азат Гайнетдиновның халыкны чиста сулы итәргә теләп башлап җибәргән эшенең тәүге җимешләре бу. Без дә яңа «Чишмә»ләрне күреп, суыннан авыз итеп кайттык.

– «Чишмә» проекты – «Приют человека» хәйрия фондының бер юнәлеше. Аның идеясе блогер Рәсүл Тавдиряковның Африкада коелар ачып йөргәнен күргәннән соң барлыкка килде. Бездә дә бар бит бу проблема, нигә әле безгә дә халыкны чиста сулы итмәскә, дидем дә, фикердәшләр табып, башлап та җибәрдек, – ди Азат Гайнетдинов.

Кызганыч, бу проблема Лаешта гына түгел, башка районнарда да бар. Шуңа да, күбрәк булсак, тагын да күбрәк кешеләргә ярдәм итәр идек, ди Азат әфәнде.

– Без бу эшне берәүгә дә әйтмичә эшли ала идек. Ләкин бу турыда сөйләвебезне мактану итеп кабул итәргә кирәкми. Безнең бары тик әлеге проектны тагын да киңәйтәсебез килә. Дәвамлы һәм саваплы эш бит бу, – диде ул.

Исеме «Чишмә» булса да, җисеме башкачарак аның. Җир астына су скважинасы бораулап, шул урынга көчле һәм бик кыйммәтле фильтр урнаштыралар. Һәм менә сиңа чип-чиста су! Шикләнүчеләр өчен фильтр аша үткән суның анализларын шунда ук элеп тә куйганнар. Аларны игътибар белән укысаң, бу суның сәламәтлек өчен дә файдалы булуын күрергә мөмкин. Һәм ул су өчен түлисе дә түгел.

Тагын бер үзенчәлек: «Чишмә»ләрне мәчет янында төзиләр. Имәнкискәдәгесен, мәсәлән, авыл имамы карап-барлап торачак. Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов әйтмешли, «Бисмилла»лы суның шифасы да күбрәк булыр.

– Бу – федераль проект та, республика проекты да түгел. Бу – тырыш эшмәкәр егетләребезнең халыкны сулы итү өчен куйган хезмәт җимеше. Бик зур рәхмәт аларга! – диде ул Имән Кискә авылында. – Монысы – райондагы дүртенче чишмә. Аның мәчет янында ачылуы иман йортын тагын да бизи, ә суның тагын да сихәтле, шифалы итә.

«Чишмә» ачылган көнне имәнкискәләр Авыл көнен дә билгеләп узды. Икеләтә бәйрәм, кыскасы. «Чишмә» ачылышына иң матур күлмәген киеп, елтыравыклы яулыгын ябып килгән Мәүва әби дә шулай ди.

– Бездәге су бик каты, кызым. Эчүен эчәбез инде, чәйнеккә юшкыны утыра. Гомерем буе чишмәле авылларга кызыгып яшәдем. Алланың биргәненә шөкер, хәзер үзебезнең дә чип-чиста сулы чишмәбез бар! – диде ул.

Мәчеттән ерак тормый икән ул, су ташырга җайлы булачак, ди. Харисовлар гаиләсенә исә юлны гына чыгасы.

– Шундый сөендек! Тизрәк чәен эчеп карыйсы килә, сез дә керми китмәгез. Бик тәмле бит суы, – диде Чәчәк апа Харисова.

«Татар-информ»/Абдул Фархан

Шуннан соң без Столбище бистәсенә бишенче «Чишмә»не ачарга кузгалдык. Анысы үткәндә-сүткәндә туктар өчен тагын да уңайлырак урында – «Султан» кафесы территориясендә урнашкан. Мәчеткә терәп үк ясалмаса да, аралары ерак түгел.

Район башлыгы сүзләренә караганда, Столбище бистәсендә су белән тәэмин ителеш – проблемалы өлкә, авырткан урын. Җирле халык саны артып тора, араларында бакчачылар да күп. Аңлашыла ки, суы да күп кирәк. Бигрәк тә җәй көне.

– Егетләребезгә рәхмәт! Бу проект дәвамлы булсын иде. Ләкин бу әле безнең өстән җаваплылык төшә дигән сүз түгел. Әлеге проблеманы хәл итәр өчен районда аз эшләнми, – диде Илдус Зарипов.

Столбищедагы «Чишмә»нең үзенчәлеге – аннан эчә торган су белән беррәттән фильтр аша узмаган су да алып була. Анысы да бушка, күпме кирәк, шуның кадәр ал.

Монда да «Чишмә» ачылу халык өчен бәйрәмгә тиң булды. Олы яшьтәге апа-абыйлар күз яшьләрен тыя алмады.

– Соңгы елларда бик тилмерәбез бит. Бик кирәк иде бу безгә. Ерактанрак килеп йөрисе булса да, суны шушыннан алачакмын, – диде Роза апа.

Халыкны «Чишмә»ле иткән егетләрнең бердәнбер үтенече бар: кем генә булса да, суга сак карасын, аның ни дәрәҗәдә кадерле булуын онытмасыннар иде!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 326

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+